**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары (муниципаль тур, 2024-2025 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 150 минут**
**Максималь балл – 45 балл**

## I. Тест биремнәре (10 балл).

1. Халык авыз иҗаты жанрлары дөрес күрсәтелгән вариантны билгеләгез (1 балл):
1) бәет, нәсер
2) дастан, бәет
3) дастан, хикәя

2. Бер яки ике вакыйгага нигезләнеп иҗат ителгән, образлар саны күп булмаган кечкенә күләмле эпик жанр (1 балл):
1) повесть
2) поэма
3) хикәя

3. Әдәби әсәрдәге кеше образларының төренә карый (1 балл):
1) җыелма
2) күчерелмә мәгънәле
3) персонаж

4. Сюжет элементы (1 балл):
1) эчке каршылык
2) композиция
3) төенләнеш

5. Әдәби әсәрдә персонажның эчке дөньясын, ягъни фикерләрен, хис-кичерешләрен, теләк-омтылышларын матур әдәбиятка хас чаралар аша тулы итеп, җентекләп сурәтләү (2 балл):

Җавап: ________________________________

6. «Акчарлаклар», «Буранда» әсәрләренең авторы (1 балл):
1) Галимҗан Ибраһимов
2) Габдулла Тукай
3) Шәриф Камал

7. Габдулла Тукайның әсәрләре генә урын алган рәтне билгеләгез (1 балл):

1) «Милләтә», «Җәйге таң хатирәсе», «Милли моңнар», «Туган тел»

2) «Кайсыгызның кулы җылы?», «Җәйге таң хатирәсе», «Милли моңнар»

3) «Милләтә», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә», «Милли моңнар»

8. *Бигрәк тә үзенә яхшы таныш булган сезонлы эшчеләр, шахтёрлар – бәхет эзләп чит җирләргә китәргә мәҗбүр булган татар халкының язмышын бөтен ваклыкларына кадәр белеп яза. Кеше күңеленең нечкәлекләрен аңлап, геройларының рухи халәтен психологик тирәнлектә ача алганлыктан, аның әсәрләреннән эчке бер моң сирпелеп тора. Ул кыска итеп, аз сүз белән тирән мәгънә җиткерә белә. Шуның белән XX гасыр башы әдәбиятын яңа тема, үзенчәлекле геройлар, сәнгатьчә сурәтләү алымнарына баета*. Кем турында сүз бара? (2 балл):

Җавап:____________________________________

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).

1. Лиро-эпик жанр буларак поэма. Поэма жанрына хас үзенчәлекләр (10 балл).

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

2. Ш.Камал иҗаты турынданиләр беләсез, аның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар? Үзенең әсәрләрендә автор нинди тема-проблемаларны күтәрә? Үзегез укыган бер әсәр мисалында аңлатыгыз (10 балл):

3. Һ.Такташның «Мокамай» поэмасыннан алынган әлеге өзектә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып языгыз (5 балл):

*Белмим,*
*Әллә күпкә,*
*Әллә бик озакка,*
*Ахры, мәңге онта алмамын*
*Тамбов урманнары уртасында*
*Усак яфраклары шаулавын...*
*Алар мәңге минем хыялымда*
*Шаулый-шаулый яфрак ярырлар,*
*Карт имәннәр, калмый минем арттан,*
*Кая барсам, озатып барырлар...*
*Бер җирдә юк андый урманнар,*
*Бер җирдә юк камыш сабаклары –*
*Андагыдай шаулый торганнар...*

*Әкияттәге ике бала кебек,*
*Каен башларына үрмәләп,*
*Ике штансыз малай дөнья белән*
*Танышып йөргән идек бергәләп...*
*Беребез сары чәчле, беребез – кара:*
*Сары чәчлесе – ул мин идем;*
*Кара чәчле, коңгырт кара күзле,*
*Кәкре аяклы дустым, җанкисәгем,*
*Ул, Мокамай бәгърем, син идең....*

______________________________________________________________________________

## III. Әдәби әсәргә анализ (10 балл).

### Алинә Бикмуллина
### Җәйнең ямьле бер көне

Менә шулай инде, 1 сентябрь дигәннәре беренчегә баручыларга (чөнки алар әле алда ниләр көткәнен чамаламый) һәм укытучыларның үзләренә генә (шуның кадәр чәчәк тагы кайчан бирерләр ди) бәйрәм ул. Калган укучылар өчен гадәти уку көне. Менә 7 нче сыйныф укучыларына бәйрәм көнне үк расписание төзеп куйганнар. Җитмәсә, ике дәрес рәттән – татар теле. Укытучылары Резедә Зөфәровна ике дәрес эчендә «Җәйнең ямьле бер көне» дигән сочинение язабыз, дигәч, ярты классның сөмсере коелды. Шундый матур көнне бозарга ул гына булдыра инде. Әнә алтынчы класслар, укытучылары белән табигать кочагында фотосессия ясап йөри, сигезенчеләр, өстәл табыннары ясап, классташлары Айратның туган көнен һәм берочтан белем көнен бәйрәм итәләр, бишенче сыйныфлар бәйрәм линейкасыннан соң өйләренә сызды, башлангычлар турында әйтеп тә торасы юк. Ә җиденчеләр сочинение яза. Адәм хурлыгы.

Шәмсинең аеруча да кәефе төште. Өйгә язарга бирсәләр, китап-мазардан күчергәләп, берәр нәрсә әвәләр иде дә – юк шул. Матур кәчтүм-чалбарлары белән мәктәпнең икенче катына да менеп җитәргә өлгермәде, озын булганга, бәйрәм линейкасында да арткы рәттә басып торды (кәчтүмнәрен күреп өлгермәгәннәрдер, шәт), шуның өстенә әле җәйдән соң шөрепләре дә нығытылмаган башка эш кушылды.

Укытучыга мин ручка-кәгазь апкилмәдем, дип тә караган иде, үч иткәндәй, күрше партадагы Ленар, мин берничәне апкилдем, дип, тизрәк яңа дәфтәр белән ручка сузды.

Беренче дәрес күз ачып йомганчы узды да китте. Бөтен кеше и язды, и язды. Шәмсинең генә башына матур уйлар килмәде, тик утырганны сизмәсеннәр, дип, кәгазьгә рәсемнәр ясап утырды. Ни турында язсын ди ул?! Җәй буе авылда ятты, ара-тирә күрше авылга әбиләренә төшкәләде. Шуннан. Тарих укытучысы Ильяс абый әйтмешли, иҗтимагый әһәмияткә ия булмаган вакыйгаларны «чебеннән фил дәрәҗәсенә күтәрү» катгый тыела.

Җиденчеләр тәнәфескә дә бүленмәде. Әйтерсең лә бөтенесенең әйтер сүзләре күбәйгән, башларын да күтәрми, әллә ничәшәр бит сыптыралар гына. Әллә барысы да кичә үк белгән инде сочинение турында, уй-фикерләрен чәчәк бәйләмнәре кебек төйнәп килгәннәр дә хәзер шуны язып утыралар, дип уйлады, кәефсезләнеп, Шәмси. Эх, ник берсе торып «бәйрәм көнне нинди сочинение инде, апа!» дип сүз башламый. Калганнары шунда ук кушылыр иде бит, укытучы да йомшарыр иде, бәлки. Юк шул, башларын игәннәр дә язалар... система коллары!

Шәмсинең башына никтер гел җәйнең ямьсез яклары гына килде. Ручкасы тик тормасын өчен, аны кәгазь өстендә арлы-бирле йөрткән булды. Яңа уку елына дип алган күлмәкләре бугазын буа башлады, тизрәк кәчтүмнәрен салып ташлап, иске футболка-шортигын киеп, мендәрен кочасы

килеп китте (бу вакытта ул бит әле йокларга күнеккән иде). Түзмәде, сикереп торып басты да сүз башлады:

– Резедә Зөфәровна, ярыймы сүз әйтсәм?

Каләм кыштырдаткан тавыш кына ишетелгән класс бер мәлгә тын калды.

– Ярый, Шәмси, әллә бетердең дәме? – дип елмайды укытучы.

– Бөтен мәктәп ял итә, тфү...бәйрәм итә. Сез генә беренче көннән үк бимазалыйсыз. Ел да шул хәл. Беренче дәрестән үк йә диктант, йә инша, йә сочинение. Ничек мин башымны эшләтергә көйлим ди инде. Аннары ни турында яза алам соң. Авылдагы хәлләрне үзегез дә белеп торасыз. Шуларны язып, юләр кебек бер-беребезгә сөйләүдән ни мәгънә? Менә минем өчен җәйнең бер ямьле көне дә булмады. Көтүгә чыктым, түбән очтагы Фөлүзә апаларның сарыклары югалды – ике тәүлек эзләгәннән соң гына таптык, шуның аркасында этидән шәп үк эләкте. Рәис абый буасына су коенырга баргач, Алмазны коткарам дип кергән идем, үзем баттым, мине коткарырга – ярда ун егет торса да – берсе дә кермәде. Һәр иртә һәм кичен унбиш сутый бакчада колорадо коңгызы чүпләдем. Үзебезнең бакча гына җитмәгән, колхоз кырына чыгып чөгендер матикладык. Аннары мәктәптә практика башланды. Мәктәп бакчасын карадык. Июльдә ай буе печәнгә йөрдек, әле безнеке генә булса бер хәл иде. Күршедәге бөтен карчыкларга булышырга туры килде. Булышмас идем дә, әни «кешедән яхшы түгел», дип, ирексезләп кертеп җибәрә. Хәтта клубка шәһәр кызларының биегәннәрен карарга чыгарга да хәл калмый иде. Шулай, Резедә Зөфәровна! Саный китсәң, хәлләрне бездә берегез дә кызыгырлык түгел. Ә сез җәйнең ямьле бер көне, дисез. Гаиләдә бердәнбер бала булгач, бик авырга туры килә. Тормыш йөге минем сыртка төшә. Ярый ла Айратның апасы үзен Казанга алып китеп гүләйт итеп апкайта; Ленарның әби-бабасы, сиксәндә булса да, бөтен эшне үзләре җимереп эшли; Алисәләр кибет тотканга вапше да балда-майда гына яшиләр... Менә алар хәзер «ямьләндерер» инде сочинениеларын. Ә мин, бишле алыр өчен ялганлап, «матур булды җәйләр, эх», дип язарга җыенмыйм. Так што, Резедә Зөфәровна...

Шәмси сүзен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, тәнәфескә чакырып, кыңгырау чылтырады. Бөтен класс, дәррәү килеп дәфтәрләрен җыеп, укытучы өстәленә өйде дә, тукталышка үзләренең автобуслары килгәнмени, ишеккә таба чаптылар. Класста укытучы белән Шәмси генә калды. Резедә апасы:

– Так что, Шәмси энем, котлыйм сине. Җәйләр үтеп китте, көзен бәрәңге аласың да башка артык эш булмас, ә бүген сиңа эш – өйдә сочинение язарга, – дип, күзенә төшкән чәчләрен рәтләп куйды да.– Онытма, иртәгә беренче дәрес – әдәбият. Җәйгә укырга биргән әсәрләргә анализ ясаячакбыз, – дип, класстан чыгып китте.

1. Шәмси образына характеристика бирегез (2 балл).
2. Әсәрдә автор нинди проблемалар күтәрә? (2 балл)
3. Әлеге әсәре белән автор укучыларга нинди фикер җиткерә? (2 балл)
4. Әлеге әсәрнең жанрын билгеләгез. Ни өчен шулай дип уйлыйсыз? (4 балл)

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары**
**(муниципаль тур, 2024-2025 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 150 минут**
**Максималь балл – 45 балл**

## I. Тест биремнәре (10 балл).

1. Халык авыз иҗаты жанрлары дөрес күрсәтелгән вариантны билгеләгез (1 балл):
1) табышмак, шигырь
2) дастан, табышмак
3) дастан, роман

2. Мәгърифәтче геройны үзәккә алган, аң-белем, тәрбия мәсьәләләре күтәрелгән әсәрләр (1 балл):
1) халык авыз иҗаты
2) мәгърифәтчелек
3) мәгърифәтчелек әдәбияты

3. Әдәби әсәрдә кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау (1 балл):
1) образ
2) портет
3) эпитет

4. Сюжет элементы (1 балл):
1) тышкы каршылык
2) хронотоп
3) чишелеш

5. Әдәби әсәрдә чагылган урын һәм вакыт бөтенлеге (2 балл):

Җавап: ______________________________

6. «Сүнгән йолдызлар», «Искәндәр» әсәрләренең авторы (1 балл):
1) Гадел Кутуй
2) Кәрим Тинчурин
3) Шәриф Камал

7. Гадел Кутуй әсәрләре урын алган рәтне билгеләгез (1 балл):
1) «Кораб», «Ана догасы»
2) «Бер хәрабәдә», «Әйтелмәгән васыять»
3) «Тапшырылмаган хатлар», «Сагыну»

8. *Искәндәр!*

*Хатымны дәвам итәм.*

*1923 ел иде. Казанда университет рабфагына укырга кердем…*

*Беренче дәресләрне тыңлау белән үк, мин бәхеттән, шатлыктан, нәрсәгә тотынырга белмичә, шашып йөри башладым. Рабфакка барганда да, кайтканда да бик еш: «Шушы урамнар, шушы коридорлар буйлап кайчандыр китап, дәфтәр тотып Ленин йөргән, шул бинада Толстой укыган. Шунда укырга дип, яшь Горький хыял корган. Шул бинадан дөньяның атаклы галимнәре чыккан. Мин укый торган бүлмәләрдә аларның да тавышлары яңгыраган», – дип уйлана башладым…* Әлеге өзек кайсы әсәрдән алынган? (2 балл):

Җавап:_________________________________

**II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).**

1. Әдәби төр буларак лирика. Лирик әсәрләргә хас үзенчәлекләр (10 балл).

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

2. Әмирхан Еники яки Фатих Әмирхан иҗаты турынданиләр беләсез? Берсен сайлап алып җавап языгыз. Аның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар? Үзенең әсәрләрендә әлеге автор нинди тема-проблемаларны күтәрә? Үзегез укыган бер әсәр мисалында аңлатыгыз (10 балл):

3. Нури Арслановның «Яз» шигырендә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып языгыз (5 балл):

*Матур чаклар!*
*Өстән энҗе тамып тора,*
*Ерганаклар,*
*Кар сулары агып тора,*
*Дымлы, салкын*
*Җирне нурга манып кына*
*Кояш алтын*
*Литаврасын кагып тора.*
*Китте кышлар*
*Мамык тунын салып кына,*
*Кайтты кошлар*
*Канатларын кагып кына,*
*Карда посып,*
*Умырзая калкып чыга,*
*Килсә гыйшык –*
*Урын калмый вак борчуга.*
*Тирәмдә ямь, –*
*Мин шул хәят тәмен беләм!*
*Шуңа сөям*
*Сезне җаным-тәнем белән.*

## III. Әдәби әсәргә анализ (10 балл).

**Алинә Бикмуллина**
**Кәрим тавык**

– Шәмси, үз-үзеңне тотышың бернинди кысаларга да сыймый, ни өчен тагы Гөлназны елаттың? – дип орышырга кереште Гөлсия Фатыйховна.

– Үзе елады, елатмадым, – дип башлаган иде, Гөлназ тагы үкереп елый башлады. – Кичә ул миннән көндәлегемне сорап торды, өй эшләрен күчереп аласы бар дип, өенә апкиткән дә көндәлекнең һәр битенә «Мин – карга!» дип язып чыккан! Тагы үксергә тотынды кыз.

– Шәмси, Гөлназ алдында гафу үтен, Гөлназ, син елама, яңа көндәлек алып бирер, ике атна эчендә алган билгеләреңне укытучылардан яңадан үзем куйдыртып чыгармын, – дип, укытучы Гөлназны тынычландырырга тырышты.

– Соң, гафу ит инде алайса, кәефеңне күтәрергә теләгән идем... – дип, Шәмси дә гаебен таныган кеше сыман кызга сүз катты.

– Миңа яңа көндәлек кирәкми, моны миңа Энҗе апам Мәскәүдән апкайтып бирде, тышын карагыз – Нюша төшкән, беренче битенә Нюша үзе автограф куйган бит анда, – дип, үксүен дәвам итте кыз.

– Соң, Гөлсия Фатыйховна, нәрсәгә үпкәләргә ди инде, бөтенебез дә кушамат белән әйтәбез бит бер-беребезгә...

– Шәмси, әниең әле кичә генә мәктәптә булды, аның өчен үзем кызарынып утырам инде, сиңа ун минут вакыт бирәм, шушы вакыт эчендә дуслашып өлгерәсез икән, молодцы, юк икән, әниеңне тагы көтеп калабыз, – дияргә дә өлгермәде укытучы, Шәмси инде аклану чарасын тапты да:

– О, минем башыма гениаль фикер килде, Гөлсия Фатыйховна! Иртәгә сишәмбе бит, димәк, иртә белән класс сәгате үтәчәк. Әйдәгез, үзем алып барам, «Кушаматлар дөньясы» дип атарбыз, бөтен классташлар үзләренең кушаматларының барлыкка килү тарихын сөйләр, кем әйтмешли, презентовать итәрләр. Менә яхшы булачак, Гөлназның гына кушаматы ямьсез түгел бит анда, әнә Рәмиснеке, мескенем, Чүптер, Илшатныкы – Махина, Илнарныкы – Баймак... Дөресен әйтергә кирәк, кеше үзе булмаганда, бөтенебез дә кушаматлап сөйлибез бит аның хакында, кушаматлар кичәсе үз кушаматыңны яратырга өйрәтәчәк. Кушамат – ул фамилиядән дә кадерлерәк бит, ни дисәң дә, бөтен нәселгә бирелә, кияүгә чыгып кына да аннан котылып булмый...

Гөлназның кәефе күтәрелсен дип кенә, укытучы да күнде:

– Классташларыңны ышандыра алсаң, әйдә соң, эшлә. Һәрберсенә өч-дүрт минут вакыт бирелер, бүген үк әзерләнә башласыннар. Класс сәгатендә кушаматлар турында сөйләү идеясе күпләргә ошады, әллә нинди әхлак-тәрбия турында сөйләтмиләр бит. Мәш килеп әзерләнделәр. Беренче булып сүзне Шәмси үзе алды:

– Безнең кушамат – Тавык, Бикмулла бабам авылда иң беренчеләрдән булып торып ишегалларын себерә-җыештыра торган булган, шуңа күрә

«тавык» дип кушамат такканнар. Бабайның дуслары мине урамда күрсә, «ти-ти-ти», дип котырта башлый, кем баласы дип кызыксынганда, үзем дә «Кәрим тавыкларныкы», дип горурланып әйтәм. Так што, сез дә, горурланып, кушаматларыгыздан оялмыйча йөрегез, – диде дә горур кыяфәт белән парта арасына кереп утырды.

Сүзне югары очтагы Күселәр нәселеннән Ләйсән алды. Төрле әйбер җыярга һәвәс булган бабасы Әхәткә кушылган икән кушаматы. Иске акчалар да җыйган ул, значоклар да, чигелгән кулъяулыклар һ.б. бик күп әйберләр. Бабалары үлгәннән соң, Ләйсәннең әнисе верандада шул җыелган әйберләрдән музей ясап куйган икән. Киләсе класс сәгатендә укучылар, «Күселәр»нең өйләренә барып, музей белән танышырга сүз куешты.

Озын сыйраклы, бик хәрәкәтчән һәм тиктормас Рания үзләрен ни өчен Чикерткә дип атауларын сөйләп тормаса да була иде инде. Аларның өйләрендә барысы да чикерткәгә охшаган бит: чәрелдәп сөйләшәләр, озын буйлылар. Хәтта киленнәре Вәсилә апа да нәкъ үзләренә охшап килгән.

Американ Фирдүс абыйларның оныклары Раил үзләренең кушаматлары турында аеруча да горурланып сөйләде, бабалары Америкада Бушның ярдәмчесе булып эшләгән диярсең. Америка әләме төсендәге бер күлмәге булган аның, гомере буе шуны киеп йөргән. Шуңа да «Американ»га әйләнгән.

Дәрес һәркемнең дә күңеленә хуш килде. Класс сәгатенең яхшы гына баруына сөенеп, укытучылары да «тавышланмагыз, хәзер керәм, сөйли торыгыз», дип, класстан чыгып китте. Көлештеләр, кул чабыштылар, оялмыйча, бер-берсенә кушаматлар белән эндәштеләр.

Отличник Айдарга сүз бирелде:

– Безнең кушамат юк, – дип сүз башлаган иде...

– Хәзер кушабыз үзебез, алай ярамый инде, – дип, бөтен класс дәррәү купты.

– Ләкин минем дә сүз аласым килеп китте. Башыма бер фикер килде...

– Сиңа гына килә инде ул фикерләр, – дип көлештеләр.

– Сезне тыңлау шундый ошады миңа, үземнең кушаматсыз нәселдән булуыма әзрәк үртәлеп тә утырдым әле. Сигезенче класслар уку елы азагына шигырь китабы әзерли дип ишеттем, әйдәгез, без «Кушаматлар китабы» әзерлибез. Ләкин китапны әзерли башлаганчы, миңа да берәр матур кушамат таксагыз иде, алайса мин керми калам бит, – дип, идеаль фикерен җиткерде.

– Кушабыз кәнишне, берне түгел, икене чәпибез әле, – диде Шәмси. – Ярый әле мин бар, мин булмасам, «Тәмәке тартуның зыяны» кебегрәк берәр темага әхлак дәресе тыңлап утырыр идегез. Әнә анда Диләрә үзенең телефонына барыгызны да яздырып бара, шуны компьютерга гына күчерәбез дә, китап та әзер була.

Соңгы сүзне Габбәзләр оныгы Динар алды.

– Безне «Габбәзләр» дип йөртәләр. Әтинең бабасы авылның зур кешесе булган, бөтен кеше аңа киңәшкә килгән, тапкырлыгы-уңганлыгы белән дан тоткан, – дип сөйли башларга да өлгермәде, классның төрле ягыннан тавыш купты:

– Шыттырма!

– Ялганчы!

– Ат карагы булган ул! Авылдагы атларны урлап, башка авылларда саткан, башка авыллардан урлап, безнең авылдагыларга сатып йөргән!

– Чын дөресен сөйләргә оятмы?! Класста купкан шау-шуга укытучы йөгереп керде. Ыжгырып килгән машиналар кызыл утлы светофор каршында туктаганмыни – бөтенесе дә «тормозларына» басты. Кушаматлар турындагы китапны эшләү идеясен укытучыга әйтеп торуның да кирәге калмады.

Елак Гөлназның кәефен күрәм, дип, Габбәз Динары белән сүзгә килү яхшыга алып бармаячагын белгәнгә, әзрәк кәефсезләнде Шәмси. Укытучылары да бүгенге класс сәгате өчен башыннан сыйпамады. Эх, ничек матур башланган иде лә бит үзе, дип уйлады ул. Беренче дәрес математикага да соңлап кына керде һәм арткы партадагы үз урынына барып утыруы булды... чалбары юешләнгәнлеген тоеп алды, басып караса – урындыкта ватык йомыркалар. Күрше партадагы Динар, кыек тешләрен ыржайтып, «дәрестә килеш тә йомырка салып утырмасаң инде, тавык!» дип көлгәндә, Шәмси инде бәрәңге бакчасыннан гына өенә төшеп җиткән иде.

1. Шәмси образына характеристика бирегез (2 балл).
2. Әсәрдә автор нинди проблемалар күтәрә? (2 балл)
3. Әлеге әсәре белән автор укучыларга нинди фикер җиткерә? (2 балл)
4. Әлеге әсәрнең жанрын билгеләгез. Ни өчен шулай дип уйлыйсыз? (4 балл)

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары (муниципаль тур, 2024-2025 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 55 балл**

## I. Тест биремнәре (10 балл).

1. Суфи идеяләрне алга куйган, илаһи мәхәббәт темасы күтәрелгән әсәрләр (1 балл):
1) суфичылык
2) дини әдәбият
3) суфичылык әдәбияты

2. Модернистик агым (1 балл):
1) импрессионизм
2) романтизм
3) реализм

3. Рун һәм уйгур язулы истәлекләр әдәбиятның кайсы чорына карый (1 балл):
1) Болгар чоры әдәбияты
2) Халык авыз иҗаты
3) Гомумтөрки әдәбият

4. Сюжет элементы (1 балл):
1) анафора
2) хронотоп
3) пролог

5. Әдәбиятны үсеш-үзгәрештә, үзенә хас закончалыклары булган процесс буларак өйрәнә торган фән (2 балл):

Җавап: ___________________________________

6. Мөхәмәдъяр, Кол Шәриф иҗатлары әдәбиятның кайсы чорына карый (1 балл):
1) Алтын Урда чоры әдәбияты
2) Казан ханлыгы чоры әдәбияты
3) Болгар чоры әдәбияты

7. Мәүла Колый әсәрләренең жанры (1 балл):
1) хикмәт
2) кыйсса
3) дастан

8. *Җәдитчелек яшәешнең икътисад һәм сәясәт өлкәләренә дә тирән үтеп керә. Гомумән, әлеге җитди үзгәрешләр татар әдәбиятына да йогынты ясый. Мәгърифәтчелек, соңрак җәдитчелек идеяләре нәкъ менә матур әдәбият аша халыкка барып ирешә. Бу яктан сүз сәнгатенең вазифасы бермә-бер арта, киңәя. Татар әдәбияты Яңарыш идеологиясен үзенә нигез итеп ала һәм реализм юлына чыга. Халык тормышына йөз тоту үзәк урынны били бара. Сүз сәнгатендә проза һәм драматургия төрләре мәйданга чыга.* Әлеге үзенчәлекләр кайсы чор әдәбиятына хас? (2 балл)

Җавап:______________________________________

**II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).**

1. Татар мәгърифәтчелек әдәбияты. Мәгърифәтчелек әдәбиятына хас үзенчәлекләр (10 балл).

___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___
___

2. Фатих Әмирхан иҗаты турынданиләр беләсез, аның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар? Үзенең әсәрләрендә ул нинди тема-проблемаларны күтәрә? Үзегез укыган бер әсәр мисалында аңлатыгыз (10 балл):

3. Муса Җәлилнең «Кызыл ромашка» шигыреннән алынган өзектә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып языгыз (5 балл):

*Иртәнге таң нурыннан*
*Уянды ромашкалар.*
*Елмаеп, хәл сорашып,*
*Күзгә-күз караштылар.*

*Назлады җил аларны,*
*Тибрәтеп ак чукларын,*
*Таң сипте өсләренә*
*Хуш исле саф чыкларын.*

*Чәчкәләр, кәефләнеп,*
*Җай гына селкенделәр.*
*Һәм кинәт шунда гаҗәп*
*Бер яңа хәл күрделәр.*

*Ерак түгел моңаеп,*
*Утыра ромашка кызы,*
*Тик чуклары ак түгел,*
*Кан шикелле кып-кызыл.*

*Ромашкалар бар да ак,*
*Аерылмый бер-береннән;*
*Ничек болай бер үзе*
*Ул кызылдан киенгән?*

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

## III. Әдәби әсәргә анализ (10 балл).

**Фатих Кәрим**
**Кыр казы**

Тирән окопта каршылыйм
Икенче язны;
Язгы таңда безнең якка
Кайта кыр казы.

Кайта диңгез артындагы
Ерак илләрдән,
Һәм яши ул төнбоеклы
Тонык күлләрдә.

Әй кыр казы, түбәнәйт тә
Очкан юлыңны,
Бүләк итеп китче миңа
Бер каурыеңны.

Каләм ясап каурыеңнан,
Язгы ялкында
Ут эченнән языйм бер җыр
Сөйгән халкыма.

Дәһшәтле сугыш кырында
Сөйгән халкымның
Мин кояшым итеп йөртәм
Йөрәк ялкынын.

Халкыма бәхет, дан даулап,
Үтә көннәрем.
Анабыз җирне кочаклап,
Бәлки, үләрмен.

Үлсәм, җырларымда калыр
Сөю, сагышлар;
Кыр казы йөзгән күлләрдә
Шаулар камышлар.

1. Лирик геройга характеристика бирегез (2 балл).
2. Хис-кичерешне җиткерү өчен автор нинди образлардан файдалана? (2 балл)
3. Әлеге әсәре белән автор укучыларга нинди фикер җиткерә? (2 балл)
4. Әлеге әсәрнең жанрын билгеләгез. Ни өчен шулай дип уйлыйсыз? (4 балл)

## IV. Иҗади бирем (10 балл).

«Җиңү көнен алып килә язлар, / Алар саный заман агышын...»

# Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары
# (муниципаль тур, 2024-2025 уку елы) 10 нчы сыйныф

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 55 балл**

## I. Тест биремнәре (10 балл).

1. Сүз сәнгатендә тупланган тәҗрибәне буыннан-буынга күчерү (1 балл):
1) дәвамчанлык
2) традиция
3) яңачалык

2. Иҗат юнәлеше төшенчәсе (1 балл):
1) романтизм
2) тәнкыйди реализм
3) экспрессионизм

3. Көлке ситуациягә корылган, нигезендә көлке конфликт яткан драма жанры (1 балл):
1) драма
2) хикәя
3) комедия

4. Сюжет элементы (1 балл):
1) тәмсил
2) метонимия
3) вакыйгалар үстерелеше

5. Сүз сәнгатенә хас сыйфатларны, билгеләрне, теоретик төшенчәләрне өйрәнә торган фән (2 балл):

Җавап: ___________________________________

6. Котб, Сәйф Сараи иҗатлары әдәбиятның кайсы чорына карый (1 балл):
1) Алтын Урда чоры әдәбияты
2) Казан ханлыгы чоры әдәбияты
3) Болгар чоры әдәбияты

7. Кол Шәрифнең «...Гафил торма», «И күңел, бил баглама...» әсәрләре кайсы жанрга карый (1 балл):

1) гражданлык лирикасы
2) газәл
3) дастан

8. *Риваятьләргә караганда, ул 1883 еллар тирәсендә Чулман буендагы шәһәрләрнең берсендә туган. Кайбер чыганакларда аның Кашан шәһәрендә тууы әйтелә. Әдипнең үлү вакытын XIII гасырның 30 еллар ахыры – 40 еллар башы дип билгелиләр. Ул башта Болгар мәмләкәтендә, соңыннан Харәземдә белем алган. Кушаматы Кол атамасы белән бәйләнгән. Хәзерге вакытта күп күчермәләре саклана торган данлыклы әсәр иҗат иткән.* Кем турында сүз бара? (2 балл)

Җавап:____________________________________

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).

1. XIX гасырда реалистик әдәбият формалашу. Бу чор реалистик әдәбиятына хас үзенчәлекләр, авторлар (10 балл).

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

2. Сәйф Сараи яки Габдулла Тукай иҗаты турынданиләр беләсез? Җавабыгызны, үзегез сайлап алып, бер әдип иҗатына бәйле языгыз. Аның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар? Үзенең әсәрләрендә ул нинди тема-проблемаларны күтәрә? Үзегез укыган бер әсәр яки әсәрләр мисалында аңлатыгыз (10 балл):

3. Муса Җәлилнең «Чәчәкләр» шигыреннән алынган өзектә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып языгыз (5 балл):

*Барыгыз болынга, балалар!*
*Йөгерегез, уйнагыз, көлегез!*
*Елмайсын күреп шат аналар,*
*Юансын боеккан күңлегез.*

*Болында күп матур чәчәкләр,*
*Барсы да татлы хуш ислеләр.*
*Нәркисләр, сөмбелләр һәм мәкләр,*
*Нәкъ сезнең ирнегез төслеләр.*

*Җил көйләп тирбәтә аларны,*
*Иркәли кояшның нурлары.*
*Алар бит изге Җир-ананың*
*Сөекле кызлары, уллары.*

*Бу җирдә күп булды сугышлар,*
*Янгыннар, явымнар, давыллар,*
*Киселде күп батыр тормышлар,*
*Янды зур калалар, авыллар...*

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

## III. Әдәби әсәргә анализ (10 балл).

**Равил Фәйзуллин**
**Җаныңныңваклыгын...**

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга.
Куркырга, өркергә
җай бар ул һаман да.
Ә бит бар кешеләр
шәхесен ватмаган,
хаклыкны сатмаган,
вөҗданны саклаган.
Әйткәннәр: тарихтан
түгелсәм түгеләм,
изелсәм изеләм, –
әмма да бөгелмәм!
Үзләре сеңсә дә,
рухлары калыккан.
...Әнә шулар үлеме
җан өрә халыкка.
Асылыңны яшереп
кыланма ни генә, –
буыннар хәтерендә
бары да чигелә!
Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга....

1. Лирик геройга характеристика бирегез (2 балл).
2. Хис-кичерешне җиткерү өчен автор нинди образлардан файдалана? (2 балл)
3. Әлеге әсәре белән автор укучыларга нинди фикер җиткерә? (2 балл)
4. Әлеге әсәрнең жанрын билгеләгез. Ни өчен шулай дип уйлыйсыз? (4 балл)

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

**IV. Иҗади бирем (10 балл).**

«Хыялларда йөрткән Җиңү таңын / Ямьле язлар алып килделәр...»

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары (муниципаль тур, 2024-2025 уку елы) 11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 55 балл**

**I. Тест биремнәре (10 балл).**

1. Яшәүнең мәгънәсен эзләүче ялгыз шәхес фаҗигасе үзәктә яткан модернистик агым (1 балл):
1) экзистенциализм
2) тәнкыйди реализм
3) романтизм

2. Иҗат юнәлеше төшенчәсе (1 балл):
1) мәгърифәтчелек реализмы
2) модернизм
3) экспрессионизм

3. Драматургиянең бер жанр формасы. Үткен интрига, гадәттән тыш эмоциональлек, яхшылык белән явызлыкның кискен каршы куелуы, әхлакый үгет-нәсихәт өстенлек итә, музыка киң кулланыла (1 балл):
1) трагедия
2) драма
3) мелодрама

4. Сюжет элементы (1 балл):
1) градация
2) хронотоп
3) эпилог

5. Ниндидер тарихи вакыйга, хәл, җәмгыятьтәге тәртип-мөнәсәбәтләр, хаксызлыкларга кагылышлы хис-кичереш сурәтләнгән лирик жанр (2 балл):

Җавап: ________________________________________

6. Фатих Хөсни, Муса Җәлил иҗатлары әдәбиятның кайсы чорына карый (1 балл):
1) XX йөз башы әдәбияты
2) Сугыштан соңгы еллар әдәбияты
3) Бөек Ватан сугышы еллары әдәбияты

7. «Хәят», «Авырган минутларда», «Иртә төшкән кар» шигырьләренең авторы (1 балл):

1) Муса Җәлил
2) Хәсән Туфан
3) Фатих Кәрим

8. *Тынгысыз җанлы, заман җилләренә сизгер шагыйрь җәмгыятьнең дөрес юлдан үсмәвен, гаделсезлекләрне күрә, йөрәк әрнүен «Ант» поэмасында шартлы, күчерелмә мәгънә, эзоп теле мөмкинлекләре ярдәмендә чагылдыра... Шул әсәре, ахыр чиктә, аны гаепләүләргә алып килә.* Кем турында сүз бара? (2 балл)

Җавап:________________________________________

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).

1. Эпик төргә хас үзенчәлекләр, жанрлары. Үзегезнең фикерләрегезне әсәрләрдән мисаллар нигезендә дәлилләп барыгыз (10 балл).

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

2. Аяз Гыйләҗев яки Мөхәммәт Мәһдиев иҗаты турынданиләр беләсез? Җавабыгызны, үзегез сайлап алып, бер әдип иҗатына бәйле языгыз. Аның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар? Үзенең әсәрләрендә ул нинди тема-проблемаларны күтәрә? Үзегез укыган бер әсәр яки әсәрләр мисалында аңлатыгыз (10 балл):

3. Муса Җәлилнең «Чәчәкләр» шигыреннән алынган өзектә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып языгыз (5 балл):

*... Сез назлап үбегез гөлләрне,*
*Хуш истән күңлегез ачылсын.*
*Җир бирде сезгә шат көннәрне,*
*Йотып тир, кан һәм яшь тамчысын.*

*Балалар, сез гөлләр үзегез,*
*Чыктыгыз калкып җир карныннан.*
*Һәм чәчәк аттыгыз, үстегез*
*Атагыз, агагыз каныннан.*

*Сез безгә шулкадәр кадерле,*
*Шулкадәр ягымлы, сөйкемле!*
*Ал таңы алдагы дәвернең*
*Йөзегездә чагыладыр шикелле.*

*Чәчәкләр, үсегез, чәчәкләр,*
*Дәрт биреп безнең шат күңелгә.*
*Сезгә бу шатлыклар, рәхәтләр*
*Бит җиңеп алынган гомергә*

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

## III. Әдәби әсәргә анализ (10 балл).

**Фатих Кәрим**
**Ант**

Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә – балам. Син әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм.

Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен,
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм...

Бәлки, соңгы тапкыр – күрештек,
Кочаклаштык, озак үбештек.
Сизә бала, карый күзләремә:
«Сакла безне!» – ди ул күңеленнән,
Ана күкрәгеннән суырып алган
Сөт тамчысы алсу иренендә.

Шушы балам өчен, синең өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен,
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм.

1. Лирик геройга характеристика бирегез (2 балл).
2. Хис-кичерешне җиткерү өчен автор нинди образлардан файдалана? (2 балл)
3. Әлеге әсәре белән автор укучыларга нинди фикер җиткерә? (2 балл)
4. Әлеге әсәрнең жанрын билгеләгез. Ни өчен шулай дип уйлыйсыз? (4 балл)

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

**IV. Иҗади бирем (10 балл).**

«Онытма син, зур сынаулар / Аша килгән бу Җиңү!»